Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Кукмара шәһәре Советы

КАРАР

2019 елның 28 ноябре №29

Физик затларның
мөлкәтенә салым турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, Кукмара шәһәре Советы карар бирде:

1. Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре территориясендә физик затларның милкенә мәҗбүри түләнергә тиешле салым билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:
1) түбәндәгеләргә карата 0,1 процент:
гаражлар һәм машина урыны;
һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык каралтылары яки корылмалар;
мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган һәм Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларында, шулай ук Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектында урнашкан гаражлар һәм машина урыннары. Әлеге ставка салым түләүче сайлавы буенча бер гаражга яки машина-урынга карата билгеләнә;
2) түбәндәгеләргә карата 0,2 процент:
фатир;
фатир өлешләре;
бүлмәләр;
3) түбәндәгеләргә карата 0,3 процент:
торак йортлар;
торак йортларның өлешләре;
составына бер генә булса да торак йорт кергән бердәм күчемсез комплекслар;
мондый объектларның проектланган билгеләнеше торак йорт булса, төгәлләнмәгән төзелеш объектлары.
4) түбәндәгеләргә карата 2 процент:
Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына;
Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына;
5) башка салым салу объектларына карата 0,5 процент.

3. Мөлкәткә салым түләүдән түбәндәге затларны азат итәргә:

1) 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнар;

2) әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балалары;

4. Ике фатирдан торган күпфатирлы бер катлы торак йорттагы фатирга милек хокукына ия физик затларга бу фатирның гомуми мәйданындагы утыз квадрат метрның кадастр бәясендә салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә ташлама билгеләргә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташламалар суммасы өлешле милектәге һәр кеше өчен әлеге фатирга милек хокукындагы өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр фатир уртак милектә булса, ташламалар суммасы уртак милектәге һәр кеше өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Шул ук вакытта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташлама суммасы исәпкә алынмаган исәпләп чыгарылган салым суммасыннан артык була алмый.

Югарыда күрсәтелгән ташламаның раслаучы документлары булып йортның кадастр паспорты яки җирле үзидарә органы тарафыннан расланган күпфатирлы бер катлы торак йортларның исемлеге торырга мөмкин.

5. Үз көчен югалткан дип танырга:

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 31 номерлы Кукмара поселок Советы карары;

«Физик затлар мөлкәтенә салымнар турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 31 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 15 июнендәге 25 номерлы Кукмара поселок Советы карары;

«Физик затлар мөлкәтенә салымнар турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 31 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 14 октябрендәге 4 номерлы Кукмара поселок Советы карары;

«Физик затлар мөлкәтенә салымнар турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 31 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 21 ноябрендәге 29 номерлы Кукмара поселок Советы карары;

«Физик затлар мөлкәтенә салымнар турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 31 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 19 июлендәге 15 номерлы Кукмара поселок Советы карары;

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, шулай ук махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

7. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән соң бер айдан да иртәрәк булмаган срокта үз көченә керә.

Кукмара шәһәре мэры С. Д. Димитриев